

«РМ Инсар районы буенча социаль яклау» каршындагы пенсионерлар очен кондезге тору бvлегендә Пасха эшләнмәләре буенча мастер-класс vткән.
Инсар районы буенча социаль яклау оешмасынын пенсионерлар һәм инвалидларнын кондезге тору бvлеге белгече Екатерина Николаевна Присяжнова барысы турында жентеклəп сойләде.
- Кондезге группабызда дəваланучы Инсар шәһәрендә гомер итvче (фотодалар) Сания Нугайбек кызы Исмаилова, Наилə Равил кызы Андреева, Кадошкино районы Латышовка авылыннан Зарифә Зиннур кызы Донская, Рима Ариф кызы Бикмурзина, шул ук районнын Потижская Слободасыннан Адилә Исмаил кызы Брюзгина белән христианнарынын яраткан һәм хормәт иткән бәйрәме - Пасха алдыннан Пасха эшләнмәләре ясау буенча мастер – классны Татьяна Петровна Кузмина уздырды. Инсар социаль кондезге бvлеге кешеләре vзләренен ижатларын, гажәеп фантазияләрен һәм осталыкларын кvрсәтеп, бәйрәмгә открыткалар, чебиләр белән мәзәк тавык һәм катыргы савытлардан тавыклар ясадылар. Нәтижәдә матур һәм оригиналь Пасха эшләнмәләре килеп чыкты, - дип сойләде Екатерина Николаевна.
«РМ Инсар районы буенча социаль яклау» каршындагы пенсионерлар очен кондезге тору бvлегендә булып vзенен алган кичерешләре белән гомерен авыл хужалыгы олкәсенә багышлаган хормәтле, кvп бvләкләр иясе Зарифә Зиннур кызы Донская бvлеште.
- Апрель аенда, табигать уянгач, инешләр буенда vсә торган талтирәкләр боре кабартып чәчәк ата башлагач, Пасха бәйрәме житә. Бу вакытта тавыкларнын кvпчелеге йомырка сала башлый, сыерлар бозаулый, сот-май кvп, табигать vзгәрә, ометләр янара, тормыш жинеләя башлаган чакта була бу бәйрәм. Бу мин vзем авыл хужалыгы олкәсендәге олы стажлы агроном буларак та әйтәм. Быел безнен Ураза бәйрәмебез дә шундый табигать уянган чакка туры килде.
Һәр бәйрәмнен vз тосе, vз йолалары, vз тәртибе бар. Бездә ир-атлар бергәләшеп мәчеткә дога кылырга барсалар, Пасхада тау башында чирәм типкән жирдә кvкәй тәгәрәтәләр, кичкә таба гармуннар белән кичке уенга жыелалар, кемнәргә нинди кунаклар кайтканны берәмтекләп белешәләр, дуслашалар. Ике бәйрәм дә - дуслык бәйрәме.  Дуслык – доньяда ин кирәкле монәсәбәтләрнен берсе. Дуслык булса гына жир шарында тынычлык хокем сорер. Дуслык белән кочле без. Кадошкино районы Латышовка авылы халкы, тирә-як кvрше авыллар халкы белән дус яшәгәнгә, элек тә Пасха бәйрәме кәефе безгә дә тәэсир итми калмый иде, бvген дә бу кәеф безгә кvчте. Мәсәлән, Мордовиянен кайбер районнарында шикелле бездә дә “Чип-чип” дигән балаларнын йомырка жыеп йоргән бәйрәме vтә. Балалар буяулы йомырка жыя; хужабикәләрнен кайберләренә шулай жырлап яки яттан сойләп тә калдыралар: “Чип-чип чебәрvк, Йомыркасы югарук. Ак тавык, кvк тавык, Ходай бирсен кvп тавык...”
Пенсионерлар очен кондезге тору бvлегендә булу минем очен унай эмоциаләр калдырды. Бирегә атнанын ике конен йордек; яшәгән урын-нарыбыздан килеп алып, китереп куйдылар. Кон тәртибе бик тә унышлы һәм уйланылган: саулыкны да ныгыттык,

кvнелләргә хуш килгән чараларда да катнаштык, бергәләп чәй эчvләре дә бер-беребезнен хәтерендә озак сакланыр. Ә Пасха бәйрәме эшләнмәләре буенча мастер-классларда vзебезгә файдалы кvнекмәләр дә алдык.
Мин олы яшьтәгеләр очен булдырылган әлеге кондезге тору бvлегендә булуым белән канәгать.

**Наилә НАСЫРОВА**